**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 17 декабрендәге 5207 номерлы карары**

**Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү турында**

1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы «Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2018 елның 6 июнендәге 7-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә ачык тыңлаулар һәм җәмәгатьчелек белән фикер алышулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 29 маендагы 5024 номерлы «Алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларын үтәү чаралары турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 23 сентябрендәге 3223 номерлы «Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия төзү турында»гы карары нигезендә, кризиска каршы штабның азык-төлек сәнәгате предприятиеләре, сәүдә челтәрләре һәм сәүдә

үзәкләре җитәкчеләре катнашында уздырылган утырышының 2022 елның 4 апрелендәге 39204/Беркетмәләр номерлы беркетмәсенең 1.3 пункты буенча, Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү мәсьәләсе буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе Р.Ф.Фазылҗановка, әлеге карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә карар күчермәсен җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 17 декабрендәге
5207 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү тәртибе**

1. Әлеге Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү тәртибе (алга таба – Тәртип) Казан шәһәре территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү кагыйдәләрен гамәлгә кертә.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

2.1. аерымланган территория – әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яисә) объектлар урнашкан бина (төзелмә, корылма) янәшәсендә урнашкан, чикләре киртә (махсус ясалган объектлар) белән билгеләнгән территория;

2.2. спорт корылмасы – физкультура чараларын һәм (яисә) спорт чараларын уздыру өчен билгеләнгән, тиешле тәртиптә хокук теркәлгән күчемсез милекнең инженерлык-төзелеш объекты;

2.3. янәшәдәге территория – аерымланган территория чикләре янәшәсендә яки 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы «Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләүне билгеләү турында»гы федераль закон нигезендә алкоголь продукциясен ваклап сату, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату тыела торган урыннарда әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән оешмалар

һәм объектлар урнашкан биналар, төзелмәләр, корылмалар, бүлмәләр янәшәсендә урнашкан территория;

2.4. сәүдә үзәге – универсаль яки махсуслаштырылган товарлар ассортиментын һәм универсаль хезмәтләр ассортиментын гамәлгә ашыручы, билгеле бер территориядә урнашкан, бер бөтен буларак планлаштырылган, төзелгән һәм идарә ителә торган һәм территориясе чикләрендә автомобильләр өчен туктап тору урыны булдырылган сәүдә предприятиеләре һәм/яки хезмәт күрсәтү предприятиеләре җыелмасы;

2.5. стационар сәүдә объекты – фундаменты җир белән нык тоташтырылган бина яки бинаның бер өлеше, корылма яки корылманың бер өлеше булып торган һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган (технологик тоташтырылган), алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырыла торган сәүдә объекты;

2.6. җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект – җәмәгать туклануы продукциясен әзерләү, җәмәгать туклануы продукциясен һәм сатып алынган товарларны (шул исәптән сәнәгатьтә җитештерелгән азык-төлек продуктларын) әзерләгән урында да, аннан читтә дә заказлар буенча куллану һәм сату өчен, шулай ук төрле өстәмә хезмәтләр, шул исәптән кулланучыларның ялын оештыру буенча хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән хуҗалык эшчәнлеге объекты;

2.7. тротуар – юлның җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм транспорт юлы өлешенә яисә велосипед юлына тоташкан яки алардан газон белән аерылган элементы;

2.8. җәяүлеләр юлы – таш, агач, җир, асфальт өслек, җир полосасының яки ясалма корылманың җәяүлеләр хәрәкәте өчен җайлаштырылган яки билгеләнгән өслеге;

2.9. җәяүлеләр өчен кичү – транспорт хәрәкәте өлешенең, трамвай юлларының махсус билгеләр һәм (яисә) тамгалар белән билгеләнгән юл аша җәяүлеләр хәрәкәте өчен бүленгән участогы;

2.10. ясалма каршылык – фунциональлеге өчен зыян китермичә күчерергә мөмкин булган объектлар (лотоклар, лавкалар, аквариумнар, вазоннар, банкоматлар, декор элементлары һ.б.);

2.11. күпфатирлы йортлар янәшәсендәге чикләр – күпфатирлы йортлар торган урыннарда ясалган җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр исәбе мәгълүматлары буенча чикләре.

3. Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләрнең чикләре түбәндәге ераклыкта билгеләнә:

3.1. белем бирү оешмалары (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш) карамагында һәм (яисә) алар файдалануында булган биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, бүлмәләрдән:

- стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 50 метр;

- җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 40 метр;

3.2. балигъ булмаганнарны укыта торган оешмалар карамагында һәм (яисә) алар файдалануында булган биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, биналардан:

- стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 50 метр;

- җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 40 метр;

3.3. Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә төп (устав) эшчәнлек төре сыйфатында медицина эшчәнлеге яисә төп (устав) эшчәнлек белән беррәттән медицина эшчәнлеге алып бара торган оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр карамагында һәм (яисә) алар файдалануында булган биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан, бүлмәләрдән:

- стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 30 метр;

- җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 25 метр;

3.4. стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта, шулай ук җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта, спорт корылмаларыннан – 30 метр;

3.5. стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта, шулай ук җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта, гаскәрләрнең хәрби позицияләреннән, полигоннардан, элемтә үзәкләреннән, хәрби частьлар урнашкан урыннардан, гаскәрләр белән идарә итү, хәрби техника, хәрби милек һәм җиһазлар урнашу һәм аларны саклау, коралларны сынау өчен билгеләнгән махсус технологик комплекслардан, биналардан һәм корылмалардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм Россия Федерациясе иминлеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүче органнарның җитештерү һәм фәнни-тикшеренү оешмалары биналарыннан һәм корылмаларыннан – 30 метр;

3.6. стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта, шулай ук җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта, вокзаллардан, аэропортлардан – 30 метр;

3.7. Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнән торган югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннардан:

- стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 50 метр;

- җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта – 40 метр.

4. Күпфатирлы йорт торган урындагы җир кишәрлеге кадастр исәбенә куелмаган яисә аның чикләре билгеләнмәгән (төгәлләштерелмәгән) очракта, күпфатирлы йорт янәшәсендәге территорияләрнең чикләре булып күпфатирлы йорттан 5 метр ераклыктагы чикләр тора.

5. Стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләрнең чикләре әлеге Тәртипнең 3.1-3.7 бүлекләрендә күрсәтелгән объектларга керү урыннарыннан билгеләнә.

Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән объектларның аерымланган территориясе булган очракта, стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган

объектларда алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләре әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән объектка керү урыныннан билгеләнә.

6. Әлеге Тәртипнең 3.1-3.3 бүлекләрендә күрсәтелгән объектлар урнашкан очракта, алкоголь продукциясен ваклап сату, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән урыннар янәшәсендәге территорияләрнең чикләре сәүдә үзәкләрендә түбәндәге биналарга керү урыныннан ара калдырып билгеләнә:

6.1. белем бирү оешмалары (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш) карамагында һәм (яисә) алар файдалануында булган биналар – 25 метр;

6.2. балигъ булмаганнарны укыта торган оешмалар карамагында һәм (яисә) алар файдалануында булган биналар – 25 метр;

6.3. Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә төп (устав) эшчәнлек төре сыйфатында медицина эшчәнлеге яисә төп (устав) эшчәнлек белән беррәттән медицина эшчәнлеге алып бара торган оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр карамагында һәм (яисә) алар файдалануында булган биналар – 25 метр.

7. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләре янәшәдәге территорияләрдән иң кыска ара буенча, тротуарлар яисә җәяүлеләр юллары буйлап (алар булмаганда – юл читләре, велосипед юллары, машина юллары кырыйлары буйлап), җәүлеләр кичүләре (алга таба – җәяүлеләр зонасы) буенча билгеләнә. Җәяүлеләр зонасы белән машина юллары кисешкәндә, ара якындагы җәяүлеләр кичүе буенча үлчәнә.

Стационар сәүдә объектында алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтә торган объектларда алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән сәүдә үзәкләрендә янәшәдәге территорияләр чикләре 6 пунктта күрсәтелгән биналарга керү (чыгу) юлыннан туры линия буенча сәүдә үзәгенең бер катында, ясалма каршылыкларны исәпкә алмыйча, килүчеләр хәрәкәте буенча билгеләнә.

8. Әлеге Тәртипнең 3, 6 пунктларында күрсәтелгән бинада, төзелмәдә, корылмада, бүлмәдә яисә аерымланган территориядә килүчеләр өчен бердән артык керү (чыгу) урыны булганда, янәшәдәге территория һәр керү (чыгу) юлыннан билгеләнә.

9. Биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда янгын куркынычсызлыгы өчен билгеләнгән, запас һәм башка керү (чыгу) урыннары янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләгәндә исәпкә алынмый.